| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ НЫРЬИНСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**<br>**РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ**<br>**НЫРЬЯ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Нырья авылы

2023 елның 28 августы № 22

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге территориясендә «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның кайбер нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» Нырья авыл җирлеге Советының 2013 елның 06 июлендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Федераль законның «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү турында» 16 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге территориясендә «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның кайбер нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» Нырья авыл җирлеге Советының 2013 елның 06 июлендәге 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлегендә балалар оешмалары, белем бирү оешмаларыннан алып, алар янәшәсендәге алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән территорияләр чикләренә кадәр араның минималь кыйммәтен – 30 метр; медицина оешмаларыннан, спорт объектларыннан, гражданнарның күпләп җыелу урыннарыннан һәм югары куркыныч чыганаклары булган урыннардан алып, алар янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән территорияләр чикләренә кадәр 30 метр итеп билгеләргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев